17 тиен

ТАТАРСТАН
КИТАП НӘШРИЯТЫ
1965

Ләбибә Ихсанова



# Робинзоннар лагеренда

Л. ИХСАНОВА



# Робинзоннар лагеренда

ХИКӘЯЛӘР

ТАТАРСТАН
КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1965

БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТА
Инв № 4004

*

Редакторы *Г. ХАНОВ*

Художнигы *С. ҚУЛЬБАҚА*

*

УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

## Эх!

Гөлшат күл буендагы каен күләгәсенә килеп утырды да малайларны көтә башлады. Қилерләрме, юкмы? Беренче очрашу әле бу, беренче тапкыр сөйләшү булачак. Беренче адым. Гөлшат уенча барысы да менә шушы сәгатьтән, менә шушы каен күләгәсенә утырып сөйләшүдән башланырга тиеш. Очы сынган гарип агач, яшел чирәм өстенә ярымйорты күләгәсен салып, тын гына утыра. Сөзәк яр буенда берүзе иркенләп үсә иде әле ул. Узган атнада яшен сугып киткән дә, югарыдагы иң зур ботагын кыеп төшергән. Ни булса да ялгыз җанга тия шул. Әнә теге яктагылары, биек тау башындагылары бер-беренә сыенып, урман шикелле үсеп утыралар. Қиртләч-киртләч күләгәләре су өстеңә төшеп, яр астына куркыныч, серле бер төс биреп торалар. Берне түгел, ун төбен кисеп кит, я шунда тоташтан биш-алтысын яшен сугып сындырсын, сизелмәс тә, күренмәс тә. Андый җиргә яшене дә кагылмыйдыр аның, җиле дә әйләнеп үтәдер. Ә менә бердәнбер агачка, бөтен яр буена ямь биреп утырган каенга бәрелү кирәк бит.

Ә малайлар килмиләр дә килмиләр. «Тәмәкенең зарары турында әңгәмә була» дигән белдерүне Гөлшат, үз кулы белән язып, кичә кичтән үк элеп куйган иде. Малайлар укыймы дип, гел шул тирәдә күзәтеп йөрде. Нәрсә язганнар дип, килеп карамаган бала калмады. Шулай да Гөлшат янына килергә уйлаган кеше юк әле. Лагерь начальнигы Гарифулла абый әйткән иде аны:

— Бик усал малайлар бит монда, сеңелем, чыгырыннан чыга башлаганнары. Қыен булмасмы? — дигән иде.

Барысын да белә Гөлшат. Укытучылар да рәтләп тыңлата алмаган балалар белән эшли белмәм дип, Гөлшат үзе дә шикләнгән иде шикләнүен. Тик комсомол

БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТА
Инв № 4004

лап куйды. Аннары, казан кайнап чыгар, ташып учакны сүндермәсен дигән булып, һаман шул тирәдә булашты.

Сашаның, моңа кадәр өй эшләрендә бөтенләй гаме булмаган малайның да, хәле начар түгел иде. Күләгә салкынында ул тәмам хәл алды, аннары палаталар арасыннан исеп торган җиләс җил дә аңа рәхәт иде. Эше дә тиз бара. Кәрзин төбендәге бәрәңгеләр кимегәннән-кими тора, малайның аяк очында бәрәңге кабыклары таудай өелә бара. Тик менә сулы чиләктәгеләре генә артык күзгә күренеп артмый.

Хәер, Сашаның анда эше юк. Пычагын таяк юнгандагы күк тоткан да ялт-йолт итеп, йөртеп кенә тора. Калҗа-калҗа бәрәңге кабыклары малайның кул астыннан очып кына төшә. Йодрык зурлыгыннан бармак башы хәтле генә калган бәрәнге, чалт итеп сулы чиләккә чума.

Ул арада:

— Бу Гарифулла шул хәтле чүпле тарыны нәрсә күреп алгандыр, тазарта-тазарта җаным чыкты... — дип лагерь начальнигын шелтәли-шелтәли, чишмә буеннан Маһинур апалары менде. — Кая, кем... китер әле бәрәңгеңне, әрчеп бетергән булсаң, салыйк.

Саша ярты чиләктән артмас бәрәңгесен күтәреп килгәч, аш пешерүче хатын аптыраудан шаккатып калды:

— И-и, ход-даем! Нәрсәләр генә эшләттең моны? Бер пот бәрәңге ие бит ул. Ашка моның нәрсәсен салыйк инде. Куян шулпасы пешермибез ләбаса!

Алмаз да башын сузып чиләк төбенә карады. Карады да сызгырып ук җибәрде:

— Һи, була икән бүген хәлләр!

Ләкин бу давылның итәге аңа да тими калмады. Маһинур апасы Алмазга да өлеш чыгарды:

— Ә син нәрсә дип, шул гомер учак янында кайнаштың? Әзрәк булышсаң кулың калыр дип курыктыңмы әллә. Барыгыз, ичмасам, күзегезне терәп тормагыз, күзгалак җыеп чыгыгыз. Кузгалак ашы итәрбез, куерак та булыр.

Малайлар урманга кереп киттеләр. Алмаз җитез малай, әллә ни арада гына агачлар арасына керә дә югала. Ә Сашаның сыдырылмаган җире калмый. Иптәше шома гына үтеп киткән җирдән дә мең бәла белән чыга. Агач ботаклары күлмәк итәгеннән дә, чалбар балагыннан да каптырып калалар. Бу Алмаз әллә юри аны шундый куе җирләргә алып керә инде.





— Алмаз дим, Алмаз! Кайтыйк инде, ә!

— Тагын әз генә җыйыйк инде,— ди Алмаз. Эссе учак янына кайтасы килми аның. Шытыр-шатыр агач сындырып, урман-чытырман арасында аю шикелле йөрүе рәхәт ич.

Бара торгач Алмазның тавышы бөтенләй ишетелмәс була. Аннары Сашаны сискәндереп, ниндидер бер кош сызгырып куя да бераздан ул да тына. Башта бу тынлыкка малайның артык исе китми. Алмаз юри шулай, иптәшен куркытыр өчен, берәр куак артына качып торадыр дип уйлый ул. Үзенең әз генә дә курыкмавын күрсәтергә теләп, агач ботакларын сындырган була. Ә үзенең колагы радиолокаторсыман, урмандагы шылт иткән тавышны да тотарга әзер тора. Ләкин тынлык озаккарак сузылгандай була. Малайның да хәрәкәтләре сүлпәнләнә. Бераздан ул үзе тынып кала һәм инде аның артык түзеп торырлык хәле калмый, елак тавыш белән:

— Ал-ма-а-з! — дип кычкырып җибәрә.

Алмаз әллә каян түгел, иптәшеннән бер-ике адым гына ераклыктагы куак артыннан тавыш бирә.

Саша килгәндә ул ниндидер бер кара таш янына чүгәләгән дә, аның төбенә үскән үләннәрне йолкып маташа иде.

— Нәрсә ул? — дип сорады Саша иптәше янына ук килеп.

— Күрмисеңмени, партизаннар кабере.

— Кит әле, таш бит ул.

— Әнә, укып кара.

Саша мүк белән капланып, яшелләнеп беткән таштагы язуны көч-хәл белән укып чыкты:

«Бирелә Совет власте өчен көрәшләрдә
һәлак булган Габдуллин һәм Иванов
иптәшләр ята».

Алар таш янында шактый озак юандылар һәм аны чистартып бетергәч кенә бу турыда вожатыйга әйтергә, иптәшләре алдында мактанып алырга булдылар.

## Бер – ноль—авангардлар файдасына

Чөгендер басуы лагерьдан ерак түгел, урманны чыгып әз генә баргач та җәелеп яткан киң кырда икән. Бер башы авыл бакчаларына ук барып терәлгән яланга карап торгач малайлар:

— Әл-лә-лә-лә! Моның бөтенесе дә безгәме? — дип куйдылар.

— Әллә әзме?

— Ә-әз! Моны эшләп бетерсәң...

— Менә карап карыйк инде, — дип, Сәфәр аларны котыртып куя, — кемнең кемлеге шуннан күренә инде.

Вожатыйның сүзенә каршы, мактанып, күкрәген сугып куя Әлфәрит:

— Бумы? Чүп бу безнең өчен!

Кешене үртәргә генә бир бу Әхмәткә. Әлфәритнең мактануын анламаганга салышып, сүзен читкә борып ала:

— Чүп шул. Чүп булмаса бер көтү малайлар китереп утаргa кушмаслар иде...

— Ягез, малайлар, суганны ял иткәндә сатарбыз. Ә хәзер, көн кыздыра башлаганчы эшкә тотыныйк.

Сәфәр кичә Әлфәриткә геолог чүкечен биреп торган иде. Әллә шуңа инде, малай артык җитезләнеп маташа. Бик дуслашып та киттеләр үзләре. Вожатыйның малайлар белән бер палатада йоклавын да яратты ахры ул.





Малайлар арасында ата шайтан булып саналган бала Сәфәрнең ярдәмчесенә әйләнеп китә язды. Әле хәзер дә ул алга сикереп чыкты.

— Әйдә, кайдан башлыйбыз?

— Кайдан башласак та безнең җир инде. Барыбер үзебез бетерәсе.

Үзләре басып торган җирдән бер рәткә тезелеп, малайлар утый да башладылар. Ярышка чыккан яшь атлар шикелле ярсып тотындылар. Аларны бераз сүрелдерү өчен, баштарак Сәфәргә тезгенне тарткалап торырга туры килде:

— Ашыкмагыз!

— Бик каударланмагыз!

— Арырсыз!

— Артыгыздан чүп калдырмагыз!

Ләкин бер ярты сәгать үткәч тә малайларның дәрте сүрелә башлады. Алларындагы җир участогы барган саен зурая, киңәясыман, күпме генә эшләсәң дә моның очына-кырыена чыгып булмассыман күренә башлады. Менә шунда Сәфәр дә, башка отрядларның вожатыйлары да үзләренең ялгышларын аңладылар. Балаларны көтүе белән җир өстенә кертеп җибәрмәскә кирәк иде аларга, һәркайсы өчен участок бүлеп бирергә дә, отрядлар арасында ярыш ачып җибәрергә кирәк иде. Өч вожатый үзара киңәшеп, бераздан балаларга ял бирергә һәм ялдан соң эшне яңа тәртип белән башларга булдылар.

Ләкин аларга озак эшләргә туры килмәде. Авыл юлында күренгән балаларның зур бер төркеме башта Сәфәрнең, аннары чөгендер утаучы малайларның игътибарын җәлеп итте. Әлек берәм-сәрәм, аннары барысы бер юлы билләрен турайтып, килүчеләрне көтеп ала башладылар. Алдарак торганнары чыдамады, килүчеләрнең каршына ук йөгереп киттеләр.

— Карагыз әле, кара, Витя бит бу! — дип кычкырып җибәрде Әлфәрит йөгереп барган җиреннән туктап. Өермә шикелле бөтерелеп килгән малайлар арасында Витя белән Барыйны күргәч, аптырап ук калды ул. Әле генә шунда, үзләре белән чөгендер утыйлар иде ләбаса. Кай арада бу малайлар арасына барып кушылганнар соң әле? Аннары кызык, нигә аларның кулларын бәйләгәннәр? Бу хәл бер Әлфәритне генә түгел, башка малайларны да, вожатыйның үзен дә шаккатырган иде.

Ул арада балалар килеп җиттеләр дә, икесе бер бауга бәйләнгән лагерь малайларын вожатый алдына китереп бастырдылар.

— Менә, алыгыз малайларыгызны, — диде арадан өлкәнрәк бер бала Витя белән Барыйның аркасына төртеп, икенче безнең авылга килеп, сугышып йөрмәсеннәр.

Аның алдына теше төшкән бер малай чәрелдәп килеп чыкты:

— Бәләкәйләлне киналга билмәбез аңалга! Безнең командил во!

Авылныкылар ягыннан тагын бер бала чыкты. Кысылма әле син, дигәндәй тешсез малайны кулыннан тартып арткарак чигендерде дә:

— Беркөн дә болыннан куып кайтарды. Мансурның җиләген түктерде, — дип, зарын сөйләргә тотынды.

Оялуы булды микән, әллә хурлануымы, Витя башын иеп, аяк очларына карап тора. Тик вакыт-вакыт кына кулын тартып, бәйләнгән бауларыннан котыласы килгәндәй итә.

— Кулларын чишегез инде, малайлар. Алар хәзер беркая да качмас, — ди Сәфәр. — Хәзер ни булганын рәтләп кенә сөйләп бирегез.

Иртәнге якта Витяның күңелендә һич начар уй юк иде. Юлда уйнап-көлеп, шаяра-шаяра иптәшләре белән бергә килде. Тик урман авызын чыгып, басу читенә җитеп туктауга, ерактагы авыл өйләрен күргәч, беркөнге





хәл, Мансурдан алынмый калган үче исенә төште. Капка башыннан карап торадыр ул, телен чыгарып Витяны үртидер, иптәш малайларына әллә ниләр ялганлап, аның яман атын сатадыр күк тоелды. Авыл үзе якын гына, йөгереп барып җитүе берни түгел. Бу хәтле ыгы-зыгы арасында кемнең барын, кемнең югын да белеп тормаслар. Витя бу турыда иң элек болай гына, шаярып кына уйлаган иде. Тора-бара ул теләге аның көчәя-көчәя ныклы бер карарга әйләнде. Ләкин үзе генә барырга шикләнә иде ул. Беркөнге шикелле урап алып, изеп ташларлар, дип тә курка иде. Шуның өчен ул янәшәсендә чөгендер утап килгән Барыйны котыртты.

Китүен киттеләр. Аларның юклыгын сизүче булмады шикелле. Авылга да тиз барып җиттеләр. Әмма дошманнарын очрата алмадылар. Авыл урамы буп-буш, тып-тын. Бөтен халык эштә ахры. Беркөнне Мансур кереп бикләнгән капкага да кагылып карадылар. Капка бикле иде. Әллә кире кайтыргамы, дип аптырап торганда гына каршы як койма башыннан бер тешсез малайның башы күренде.

— Мансул абыйлал су коенылга төшеп киттеләл. Күлсәтимме?

Барыйлар авыз ачып сүз әйтергә өлгерми калдылар, малай капка астыннан шуып чыгып, алар янына килеп тә туктады.

Елга буе ерак та түгел икән. Тешсезләрнең өй буендагы тыкрыктан төшүгә үк башлана. Шунда, тыкрык башыннан аз гына югарырак менгәч, яртылаш суга ауган карт өянке төбендә Мансурлар кармак белән балык

Ихсанова Дабиба Фаизовна

*В ЛАГЕРЕ РОБИНЗОНОВ*

(на татарском языке)

Художество редакторы Б. М. Әлменов
Техник редакторы З. А. Ибраһимова
Корректорлары Р. С. Хамидуллина,
М. М. Мирсалихова

Наборга бирелде 26/VIII-65 ел. Басарга кул куелды 23/XI-65 ел. ПФ 16480. Кәгазь форматы $84 \times 108^{1}/_{32}$. Учетн.-изд. табагы 5,8. Басма табагы 3,63(6,09). Заказ Л-1118. Тираж 6000. Бәясе 17 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19, 1965.